Казан шәһәре Совет районының муниципаль автоном мәктәпкәчә белем учреждениесе
«Катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 261нче номерлы балалар бакчасы»

Педагогик киңәшмә утырышында
каралды һәм кабул ителде
«29» 08 2022г
1 нче номерлы беркетмә.

«Раслыйм»
МБМББУ №261нче балалар бакчасы»
мөдире Сунгатуллина Т.Г.
Пр. № 780 от «01» 09 2022г.

# Балалар бакчасында рус һәм башка милләт балаларына татар теле өйрәтү программасы

**2022 – 2023 уку елы**

Төзүчесе: 1 нче.категорияле
татар теле тәрбиячесе
Шайдуллина А.В.

**Эчтәлек**


| | | |
|---|---|---|
| **Аңлатма язуы** | | |
| **I НЧЕ БҮЛЕК. Максатчан бүлек** | | |
| 1.1 | Программаның максаты һәм бурычлары | |
| 1.2. | Программа принциплары | |
| 1.3 | Балаларның яшь үзенчәлекләре | |
| 1.4 | Укыту методик комплектының эчтәлеге. | |
| 1.5 | “Татарча сөйләшәбез”укыту методик -комплектлары буенча үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр.Күзәтү | |
| 1.5.1 | Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) | |
| 1.5.2 | Зурлар төркеме (5-6 яшь) | |
| 1.5.3 | Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) | |
| 1.5.4 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның татар телендә сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен күзәтү | |
| 1.6 | Балаларны милли,мәдәни мөхит гадәтләре һәм нормаларына кунектерү | |
| **II НЧЕ БҮЛЕК. Эчтәлекле** | | |
| 2.1 | Белем бирү эшчәнлегенең күләме. | |
| 2.2. | Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар. | |
| 2.3 | Эш төрләре һәм формалары. | |
| 2.4 | Инновацион эш | |
| 2.5 | Электрон чаралар куллану ярдәмендә белем бирү режимы | |
| **III НЧЕ БҮЛЕК. Оештыру** | | |
| 3.1 | Материаль – техник яктан тәэмин ителеш | |
| 3.2 | Программалар белән һәм методик яктан тәэмин ителеш | |
| 3.3 | Кулланылган әдәбият | |
| | **Кушымта** | |
| 1 | Белем бирү эшчәнлекләре челтәре | |
| 2 | Тәрбиячөнең эш көне бүленеше | |
| 3 | Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге | |
| 4 | Педагоглар белән бердәм эшчәнлек | |
| 5 | Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның әти-әниләре белән бердәм эшчәнлеге | |
| 6 | куңел ачу, бәйрәмнәр | |
| 7 | Күзәтү материаллары | |
| 8 | укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар | |
| | | |

**Аңлатма язуы**

Эш программасы Казан шәһәре Совет районының муниципаль автоном мәктәпкәчә белем учреждениесе «Катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 261 нче номерлы балалар бакчасы» өчен төзелгән.

Балалар бакчасында рус балаларына татар телен өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү, төрле яктан үсеш өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:

**Федераль җирлектә:**

-“Россия Федерациясендә белем турында” федераль закон - 29.12.2012 N 273-ФЗ (07.05.2013 үзгәртүләр кертелеп, 19.05.2013 гамәлгә кергән),

-Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Министрлыгы һәм Фән министрлыгының 2013 елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган;

СП 2.4.3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденными постановлением главного санитарного врача от 28.09.2020 № 28 приказом Минобрнауки от 31.07.2020 № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования»,-“ (Тәрҗемәсе СП 2.4.3648-20 “Балалар һәм яшьләр өчен төзелгән тәрбия һәм белем бирү, ял һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар –эпидемиологик таләпләр “ баш санитар табип карары нигезендә раслана 28.09.2020 № 28, “Оештыру тәртибен белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыру төп белем бирү программасы- мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә раслау" Минобрнаук приказы 31.07.2020 №373

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының 2013 ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы;

-Мәгариф һәм Фән Министрлыгының туган һәм татар телләрен балалар бакчаларында өйрәтү эшчәнлеге буенча методик тәкъдимнәре буенча боерыгы ( 2018ел)

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2015–2025 елларда мәгарифне үстерү стратегиясе (29.05.2015, №996-р)

**Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җирлегендә:**-Казан шәһәре Совет районы «Катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 261нче номерлы балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе уставы;

- Казан шәһәре Совет районы «Катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 261нче номерлы балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе.

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус телле балаларны татарчага өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы (эш программасы) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре”нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары нигезендә расланган) нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле һәм башка милләт балаларын татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. З.М.Зарипова авторлыгында “Татарча сэйләшәбез” укыту-методик кулланмаларына нигезләнеп өйрәтелә. УМК“Минем өем” (4-5 яшь), “Уйный – уйный үсәбез” (5-6 яшь), “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” (6 - 7 яшь) проектларын үз эченә ала.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртелә, яңа алымнар кертелә, баетыла.

Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Эш программасы өч бүлектән (максатчан, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

Эш программасының кушымта өлешендә эш көне бүленеше, шөгыльләр челтәре, еллык эш план , милли состав .

## I БҮЛЕК. Максатчан бүлек

**1.1. Программаның максаты:**

Татар теленә өйрәтү “Татарча сөйләшәбез”(авторлары З.М.Зарипова, Р. Г. Кидрячева, Р.С.Исаева) укыту-методик комплектында каралган рус телле балаларгататар теленөйрәнүгәкызыксыну уяту,материални ныклап үзләштерүһәмлексик минимумны ныгыту эшенә ярдәм итү или юнәлдерү(способствовать)

**Программаның бурычлары :**

-сүзлек байлыгын арттыру, сөйләмдә сүзләрне актуальләштерү

-беренчел диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү күнекмәләрен булдыру;

-хәтер, игътибарлылык, фикерләү ,ишетү сәләтен үстерү;

-татар телен өйрәнугә кызыксыну уяту;

-аралашу теләге булдыру;
-халык авыз иҗаты аша башка халыклар мәдәниятына карата кызыксыну һәм хөрмәт хисе уяту.

**1.2. Программа принциплары:**

*Коммуникативлык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү;

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасының башлангыч мәктәп белән эзлеклелеген күздә тоту;

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү.

*Интеграция принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү.

**1.3. Балаларның яшь үзенчәлекләре**

**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)**

Бу яшьтә баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуда мөстәкыйльлеге үсеш ала. Балалар өлкәннәр белән практик эшләрдә (йомыш үтәү, күмәк уеннар) аралашуны дәвам итү өстенә интеллектуаль аралашуга да омтылалар. Бу күпсанлы сораулар (Нигә?, Ни өчен?, Нәрсә өчен?) бирүдә һәм өлкәннәрдән яңа информация алырга теләүдә күренә. Балаларның сүзлегендә теләктәшлек, кеше хәленә керә белү, кызгану сүзләре барлыкка килә. Яшьтәшләрен үзләренә җәлеп итү өчен балалар аралашуның ситуациясенә карап, интонация, ритм, сүз тизлеген җайлыйлар. Өлкәннәр белән аралашу вакытында сөйләм этикеты кагыйдәләрен үтәп, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, юату, кызгану, кеше хәленә керә белү сүзләрен кулланалар. Бу яшьтә баланың сөйләме бәйләнешле һәм эзлекле була.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)**

Алтынчы яшьтә баланың сөйләм үсешендә мөһим үзгәрешләр барлыкка килә.
Авазларны дөрес әйтү бу яшьтә норма булып тора. Балаларда (чит телгә), татар теленә карата кызыксынулары арта, шул телдә сөйләшергә, җырларга, аудио – видеоязмалар тыңларга, телевизион тапшырулар карарга теләкләре үсә. Балалар сөйләмдә гомумиләштерүче, күпмәгънәле сүзләр, антонимнар, синонимнар куллана башлыйлар. Аларның сүзлеге профессияне, социаль учреждениеләрне аңлатучы сүзләр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына баетыла. Балалар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнеп,

мөстәкыйль рәвештә уенлы һәм эшлекле диалоглар төзергә, туры һәм кыек сөйләмне кулланырга өйрәнәләр, тасвирлау һәм хикәяләү монологында геройның хәлен, кәефен, эпитетлар һәм чагыштырулар кулланып, бирергә сәләтле. Балалар үзара кара – каршы сөйләшергә, үзләренә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм шулай ук тиешле репликаны кулланып җавап бирергә сәләтлеләр. Бу яшьтәге балалар уен ситуацияләре, проблемалы – эзләнүле уен ситуациләрен барлыкка китереп, күрсәтмә әсбаплар, мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**

Бу яшьтә баланың сөйләме төрле контингент кешеләре белән аралашуга мөмкинлек бирә. Балалар авазларны дөрес әйтү генә түгел, фонемаларны һәм сүзләрне таныйлар. Телнең морфологик системасын үзләштерү аларга исемнәрнең, фигыльләрнең һәм сыйфатларның катлаулы грамматик формаларын төзергә мөмкинлек бирә. Чит телгә карата тотрыклы кызыксыну үсә. Мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр, аудио – видеоязмалар, уку – укыту методик комплектларын кулланып предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне һәм сүзтезмәләрне сөйләмдә, аралашуда актив кулланалар. Гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре белән балаларның лексикасы баей, сүз байлыклары арта. Бу яшьтәге балалар төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзиләр. Татар телендә сөйләшүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белергә, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышалар. Телне аз белүләренә дә карамастан диалогларда катнашырга омтылалар. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары бик еш сөйләмдә катлаулы җөмләләр кулланалар. 6—7 яшьтә баланың сүз байлыгы арта. Диалог төзегәндә бала сорауларга тулы җавап бирергә, үзе сораулар бирергә, әңгәмәдәшен аңларга тырыша. Монологик сөйләм дә актив рәвештә үсә. Балалар эзлекле һәм бәйләнешле итеп сөйли алалар.

**1.4.Укыту методик комплектының эчтәлеге.**

Һәр проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар һәм эти-әниләр өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоязмалар;
5) анимацион күренешләр;
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

**“Татарча сөйләшәбез” проекты**

**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)“Минем өем” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

1. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

2.Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклар хисабына сүз байлыгын арттыру.

3.Тәрбияче кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.

4. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)“Уйный – уйный үсәбез” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

1. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

2.Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.

3.Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.

4.Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

5. Диалогик сөйләмне фикер йөртү, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**

**“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

1. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү , балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

2. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.

3.Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

4. Диалогик һәм монологик сөйләмне, фикер йөртү, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

**1.5 “Татарча сөйләшәбез”укыту методик -комплектлары буенча үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр.Күзәтү**

**1.5.1 Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) “Минем өем” проекты.**

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Балалар ел ахырына “Минем өем” проекты темалары буенча 62 сүз үзләштерә.

Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.

Өйрәнгән сүзләрне, кыска фразаларны аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.

Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.

Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.

Раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.

Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

Татар телендә сөйләшү теләге бар.

### 1.5.2 Зурлар төркеме (5-6 яшь)
### “Уйный – уйный үсәбез” проекты

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Балалар ел ахырына “Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары хисабына үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта 107 сүз кулланып татар телендә аралаша.

“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

*Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?* соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

### 1.5.3 Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)
### “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре:**

Балалар ел ахырына “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары хисабына үзара һәм зурлар белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

*Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың*? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана.

### 1.5.4. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның татар телендә сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен күзәтү

Балаларның татар телендә аңлау һәм сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен уку елы башында (сентябрьнең соңгы атнасы) һәм уку елы ахырында (апрельнең соңгы атнасы) күзәтелә. Уртанчылар төркеме балалары белән күзәтү уку елы ахырында үткәрелә.

Күзәтүне һәр бала белән аерым, 1–2 бала катнашында, ә йомгаклау эшчәнлеге булганда барлык балалар белән бергә дә үткәрелә. Күзәтү вакыты 10-15 минут бара.

Биремнәр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә, уен-бирем рус телендә аңлатыла. Биремнәр мавыктыргыч һәм кызыклы итеп төзелә. Сораулар ачык, төгәл итеп, интонация белән бирелә. Тәрбияче бала әйтә алмаганда булышырга тиеш.

Күзәтү барышында яңа материал бирелми. Күзәтүне таратма, күрсәтмә рәсемнәр, интерактив тактада уеннар кулланып уткәрелә.

Биремнәр, уеннар өчен кирәк булган күрсәтмәлелек алдан әзерләнеп куела. Тәрбияче һәр биремгә аерым балл куеп бара. Күзәтү ахырында баллар саны кушыла һәм 5 кә бүленә. Шулай итеп, гомуми нәтиҗә ясала.

**Уртанчылар (уку елы ахырында),зурлар(уку елы башында) төркеме балаларының “Минем өем” проекты**

| № | Баланың исем фамилиясе | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Балл | Дәрәҗә |
| | | “ Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. “ Бу кем? Бу нәрсә? Сорауларына җавап бирү | Ягымлы сүзләр куллану (“ исәнме” , ” Исәнмесез” , ” Саубул” , ” С аубулыгыз” , ” Хәлләр ничек?” , ” Рәхмәт” ) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү(кил, утыр, эч, уйна, сикер, аша, ю) | Тирә-юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. “ Нинди?” соравына җавап бирү | Аралаша белү ( ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәгъдим итү, инкар итү, раслау). | | |
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |

**Зурлар (уку елы ахырында) һәм мәктәпкә әзерлек төркеме (уку елы башында) балаларының “Уйный – уйный үсәбез” проекты**

| № | Баланың исем фамилиясе | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Балл | Дәрәҗә |
| | | “ Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“ исәнме” , “ сау бул” , “ рәхмәт” . “ исәнмесез” , “ саубулыгыз” ) | Боерыкны аңлап үтәү (кил, утыр, эч, уйна, сикер, аша, ю) | Тирә-юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. “ Нинди?” соравына җавап бирү | Аралаша белү, ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәгъдим итү, инкар итү, раслау. | | |
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Без инде хәзер зурлар, - мәктәпкә илтә юллар” проекты**

| № | Баланың исем фамилиясе | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Балл | Дәрәҗә |
| | | “ Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. | Ягымлы сүзләр куллану (“ исәнме” , “ исәнмесез” , “ сау бул” , “ сау булыгыз” , “ рәхмәт” , “ зур | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, жырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?).Ничә яшь?( | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, | | |
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

| Нәтиҗәләрне бәяләү | |
|---|---|
| **Югары дәрәҗә**<br>2,7 - 3кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, диалогта үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| **Уртача дәрәҗә**<br>2- 2,6 кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| **Уртачадан түбән дәрәҗә**<br>1-1,9 га кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен күзәтүдә кулланырга мөмкин булган биремнәр кушымтада бирелә.(кушымта №5)

### 1.6 Балаларны милли,мәдәни мөхит гадәтләре һәм нормаларына кунектерү

Максат: туган як турында тулы күзаллау формалаштыру.

Бурычлар :

-туган шәһәрнең барлыкка килү тарихын өйрәнүгә теләк уяту;

-туган якны данлаган күренекле якташлар белән таныштыру;

-туган якның истәлекле урыннары, үсемлек һәм хайваннар дөньясы , Кызыл китабы хакында күзаллау формалаштыру;

-туган өй,гаилә,ата-аналарга һәм аларның хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләү;

-туган якның халык иҗаты, милли бәйрәмнәре белән таныштыру;

Әлеге максат,бурычлар Р.К.Шәехованың “Сөенеч”программасы аша тормышка ашырыла.

## II БҮЛЕК. Эчтәлекле

### 2.1 Белем бирү эшчәнлегенең күләме.

| Төркемнәр | Дәвамлыгы | Белем бирү эшчәнлеге | Режим момен-тында эшчәнлек | Елга | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| Уртанчылар төркеме– 4 яшьтән 5 яшькә кадәр; | 20 минут | - | 3 | 108 | |
| Зурлар төркеме(5 яшьтән 6 яшькә кадәр) | 25 минут | 2 | 1 | 108 | |
| Мәктәпкә хәзерлек төркеме( 6 яшьтән 7 яшькә кадәр.) | 30 минут | 2 | 1 | 108 | |

Уртанчылыр төркемендә белем бирү эшчәнлеге иртәнге вакыт аралыгында, саф һавада йөргәндә, кичке вакыт аралыгында режим моменты буларак атнага өч тапкыр үткәрелә.

Зурлар төркемендә ике эшчәнлек белем бирү эшчәнлеге буларак үткәрелсә, өченчесе иртәнге вакыт аралыгында, саф һавада йөргәндә, кичке вакыт аралыгында режим моменты буларак үткәрелә.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә ике эшчәнлек белем бирү эшчәнлеге буларак үткәрелсә, өченчесе иртәнге вакыт аралыгында, саф һавада йөргәндә, кичке вакыт аралыгында режим моменты буларак үткәрелә.

Режим вакытында иң зур игътибарны дидактик, үстерелешле уеннарга , сүзле күнегүләргә,театраль эшчәнлеккә, әйлән- бәйлән, аз хәрәкәтчән уеннарга; өстәл, сюжетлы- рольле уеннарга, шигырь ятлауга, дәфтәрләрдә эшләүгә; юл йөрү кагыйдәләрен һәм шәһәр урамында үз- үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгытуга; бармак уеннары, вак моториканы үстерү уеннарына, сүз байлыгын үстерү уеннарына юнәлтү кирәк.

**2.2.Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.**

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

Темалар бер-берсенә бәйләнешле итеп, балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган. Белем бирү эшчәнлекләренең темасы катлауландырылып, кабатлана бара, алар баланың сөйләм телен камилләштерү максатын күздә тотып төзелгән. Һәр теманы йомгаклау өчен, гомумиләштерү эшчәнлеге буларак, аудио язмалар, анимацион күренешләр дә эшләнгән. Телгә өйрәтүнең төп формасы һәм чарасы булып белем бирү эшчәнлеге алына. Ул системалы рәвештә план буенча үткәрелә, Планга индивидуаль эш тә кертелә. Өйрәнелгән сүзләр, сүзтезмәләр, диалоглар эшчәнлектән тыш уен вакытларында активлаштырыла һәм ныгытыла, көндәлек аралашуда кулланыла. Яңа сүзләрне, сүзтезмәләрне, ситуацияләрне балалар аңламаган очракта, тәрбияче рус телендә аңлата. Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән таныштырганда киң кулланыла. Балаларга темадан тыш артык сүзләр, уеннар, җырлар, шигырьләр төп программаны үзләштергән очракта бирелә. Бала татар телендә сүзне дөрес әйтмәгән очракта, тәрбияче баланы тыңлап сүзнең дөрес үрнәген бирә. Балалардан авазларның дөрес әйтелешен катгый таләп ителми.

**2.3.Эш төрләре һәм формалары.**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.

3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (эти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 2.4 Инновацион эш

Яшәешне электрон технологияләре чолгап алган бу заманда балаларга белем бирү процессы да үзгәрешсез кала алмый.

Рус балаларына татар теле өйрәтүдә ИКТ технологиялар эшчәнлекне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештырырга ярдәм итә.

## 2.5.Электрон чаралар куллану ярдәмендә белем бирү режимы

| **Белем бирүдә электрон чаралар** | **Баланың яше** | **Дәвамчанлык, минутларда., артык түгел** | |
|---|---|---|---|
| | | **Бер эшчәнлектә** | **Бер көндә** |
| Интерактив такта | 5-7 | 7 | 20 |
| Интерактив панель | 5-7 | 5 | 10 |
| Персональ компьютер, ноутбук | 6-7 | 15 | 20 |
| Планшет | 6-7 | 10 | 10 |

Электрон чаралар куллану ярдәмендә белем бирү биш яшьтән алып башлана. Эшчәнлектә төрле типтагы электрон чаралар куллануның өзлексез дәвамлылыгы
5-7 яшьлек балалар өчен электрон чаралар куллануның өзлексез дәвамлылыгы. Өйрәтү характерындагы фильм яки башка информацияне эш дәфтәрләренә теркәү күздә тотылса 5-7 минут вакыт бирелә .Наушниклар куллану 1 сәгатьтән артмаска тиеш. Тавыш дәрәҗәсе 60% ка кадәр мөмкин. Электрон чаралар кулланганда күзгә гимнастика уткерәлә.

## III БҮЛЕК. Оештыру.
### 3.1.Материаль - техник яктан тәэмин ителеш

| | | |
|---|---|---|
| Татар теле кабинеты | Белем бирү эшчәнлеге эшкәртмәләре,диагностик материаллар ,индивидуаль эш, ата-аналар, педагоглар өчен консультацияләр, ачык эшчәнлекләр . | Зурлар һәм балалар өчен өстәлләр, урындыклар, экран, ноутбук, проектор, дидактик, интерактив уеннар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар,балалар әдәбияты, тематик папкалар, альбомнар, укыту -методик комплект (демонстрацион, таратма материал(Кушымта №5), аудио, видео дисклар, маскалар, театрларның төрле төрләре), Символик график күрсәтмәлелек, күләмле күрсәтмәлелек ( макетлар , муляжлар , уенчыклар , эш дәфтәрләре .ТР һәм РФ символикасы. |

### 3.2. Программалар белән һәм методик яктан тәэмин ителеш

**Татарча сойлэшэбез укыту- методик комплекты:**

**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь):**

- Методик кулланма “Минем өем”
- Эш дәфтәре “Минем өем” (17 бирем)
- (аудиоязма) “Минем өем” (64 кисәк )(комп)
- Күрсәтмә һәм таратма материал (папка)

**Зурлар төркеме (5-6 яшь):**

- Методик кулланма “Уйный-уйный үсәбез”
- Эш дәфтәре “Уйный-уйный үсәбез” ( бирем)
- (аудиоязма) “Уйный-уйный үсәбез” (63 кисәк)(комп)
- Күрсәтмә һәм таратма материал (папка)

**Мәктәпкә әзерлек төркеме 6-7 яшь:**

- Методик кулланма “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”
- Эш дәфтәре “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” ( бирем)
- (аудиоязма) “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” )(комп)
- Күрсәтмә һәм таратма материал (папка)

Укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар ...нче кушымтада бирелгән.

**Программалар.**

-К.В. Закирова “Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү”. Программаның милли-төбәк юнәлеше». Казан, “Мәгариф” нәшрияты,2009.

Н.Е.Веракса, М.А. Васильева, Т.С. Комарова редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнеӊ якынча төп белем бирү программасы

-Зарипова З.М. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. “Идел-Пресс”, 2013.

-З.М. Зарипова, Р.С.Исаева, Р.Г. Кидрячева һ.б. “Балалар бакчасында рус балаларына татар телен өйрәтү: программа, методик киңәшләр, диагностика” 2013 ел.

- Р.К. Шаехова “Сөенеч- Радость познания” региональ мәктәпкәчә белем бирү программасы, 2016 ел.
- Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр”. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы”

**Методик кулланмалар**

1.К. В. Закирова, Л. Р. Мортазина “Балачак-уйнап,көлеп үсәр чак”, Казан 2012 (балалар бакчасында уеннар)
3.К. В. Закирова төзүчесе “Балачак аланы”, Казан 2011 (балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия)
4. К. В. Закирова автор-составитель “На поляне детства”, Казань 2011 (хрестоматия для воспитателей дошкольно образовательных учреждений и родителей)
5.К.В. Закирова“Әй уйныйбыз, уйныйбыз...” Методик кулланма.
6.З.М.Зарипова“Үстерешле уеннар” Методик кулланма.
7.К.В.Закирова «Әхлак нигезе – матур гадәт». Методик кулланма. Казан, 2004
8.К.В.Закирова “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе”. Методик кулланма.
9.З.Г. Ибрагимова «Шома бас». Методик кулланма.
10. 11. З.М.Зарипова «Планирование деятельности по обучению дошкольников татарскому языку». Методическое пособие. Казань, 2018.
12.«Татарча сөйләшәбез. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү». Методик ярдәмлек. Казан, 2011
13.«Татарча сөйләшәбез. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү». Методик ярдәмлек. Казан, 2011
14.«Татарча сөйләшәбез. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү». Методик ярдәмлек. Казан, 2011

**Тавышлы күрсәтмәлелек**

Зарипова З.М. “Минем өем” проеты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”, проекты буенча 6-7 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012
Зарипова З.М. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012

**3.3 Файдаланылган әдәбият:**

*Борһанова Р. А., Юсупов Ф. Ф.* Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. – Казан: РИЦ «Школа», 2004.
Демихова Л.Ю. Разработка модели рабочей программы воспитателя.-Издательство “ТЦ СФЕРА”Зарипова З. М., Исаева Р. С., Кидрячева Р. Г ...Планирование деятельности по обучению дошкольников татарскому языку.Методическое пособие.,Казань “Хэтер” , 2018

**Приложение №1**

***Дүшәмбе***

*8.05- 8.35* *5 нче мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

**8.50- 9.50** **13 нче зурлар төркеме (9.00, 9.35)**

*9.55-10.15* *1 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында)*

***10.20-10.45*** ***3 мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)***

*10.50-11.20* *6 нчы мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

*11.25-12.00* *7 нчы мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

***15.20- 16.25*** *11 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында) (15.20, 16.05)*

**Сишәмбе**

**8.05 - 8.35** **6 нчы мәктәпкә хәзерлек төркеме (1т.)**

**8.55 - 9.25** **6 нчы мәктәпкә хәзерлек төркеме (2т.)**

**9.30 - 9.55** **4 нче зурлар төркеме**

***10.00 -10.40*** ***7 нче мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)***

*10.45 -11.05* *11 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында)*

*11.10 -11.30* *12 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында)*

**Чәршәмбе**

*8.05 - 8.25* *11 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында)*

**8.50 – 10.00** **3 мәктәпкә хәзерлек төркеме (8.50, 9.30)**

*10.05 -10.50* *1 нчы уртанчылар төркеме (10.05, 10.30)*

*10.55 -11.25* *6 нче мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

*11.30-12.00* *5 нче мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

***15.20- 16.25*** *12 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында) (15.20, 16.05)*

**Пәнҗешәмбе**

**8.05 - 8.25** *1 нче уртанчылар төркеме (режим вакытында)*

**8.50 – 10.00** **7 мәктәпкә хәзерлек төркеме (8.50, 9.30)**

**10.05 -10.35** **6 нчы мәктәпкә хәзерлек төркеме**

*10.40-11.00* *3 мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

*11.05-11.30* *13 нче зурлар төркеме (режим вакытында)*

*11.35-12.00* *4 нче зурлар төркеме(режим вакытында)*

**Җомга**

**8.50-10.00** **5 мәктәпкә хәзерлек төркеме (8.50, 9.30)**

**10.05-10.30** **13 нче зурлар төркеме**

*11.35- 12.00* *12 нче мәктәпкә хәзерлек төркеме (режим вакытында)*

**15.20- 16.30** **4 нче зурлар төркеме (15.20, 16.05)**

**Приложение №2**

## Уртанчылар төркеменең «Минем өем» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар

| | | |
|---|---|---|
| 1.А4 форматында күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 1 данә |
| | Зур уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.<br>курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина – пычрак уенчыклар. | Һәрберсе 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: «Куян өйгә керә, өйдә аю утыра». «Куян өйдән чыга, саубуллаша». | Һәрберсе 1 данә |
| | Рәсемнәр: 1 куян, 2 куян, 3 куян, 4 куян, 5 куян;<br>1 аю, 2 аю, 3 аю, 4 аю, 5 аю;<br>1 курчак, 2 курчак, 3 курчак, 4 курчак, 5 курчак;<br>1 туп, 2 туп, 3 туп, 4 туп, 5 туп;<br>1 машина, 2 машина, 3 машина, 4 машина, 5 машина;<br>1 песи, 2 песи, 3 песи, 4 песи, 5 песи;<br>1 эт, 2 эт, 3 эт, 4 эт, 5 эт. | Һәрберсе 1 данә |
| 2.А3 форматында өй рәсеме. | Өй макеты | 1 данә |
| 3. А 5 форматында таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Ипи, алма, чәй, сөт. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. | Һәрберсе 15 данә |
| 4. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, куян, аю, песи, эт. | Һәрберсе 15 данә |
| | Бармак уеннары өчен атрибутлар: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт Акбай, песи Мияу, аю, куян. | Һәрберсе 15 данә |

**Зурлар төркеменең «Уйный-уйный үсәбез» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар.**

| | | |
|---|---|---|
| 1. Күрсәтмә рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәр («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Ашамлыклар»<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Савыт-саба»<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Җиләк-җимешләр»<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Яшелчәләр»<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Киемнәр»<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Өй җиһазлары»<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | «Төсләр»<br>Палитра: зәңгәр, кызыл, сары, яшел. | Һәрберсе 1 данә |
| | «Саннар»<br>10) | Һәрберсе 1 данә |
| 2. Таратма рәсемнәр. | «Минем гаилә»<br>Малай, кыз рәсемнәре: («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Уенчыклар»<br>Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |

| | | |
|---|---|---|
| | Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | |
| | «Ашамлыклар»<br>Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Савыт-саба»<br>Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Җиләк-җимешләр»<br>Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.<br>Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Яшелчәләр»<br>Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.<br>Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. | Һәрберсе 15 данә |
| | «Киемнәр»<br>Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | «Өй җиһазлары»<br>Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).<br>Кечкенә рәсемнәр: кровать, стул, стол - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| 3.Буяу өчен график рәсемнәр | 1 аю, 2 куян, 2 машина, 2 курчак, 3 бәрәңге, 4 кәбестә, 4 курчак, 5 песи, 6 алма, 6 кыяр, 7 туп, 7 бәрәңге, 8 кишер, 9 суган, 10 эт. | Һәрберсе 15 данә |
| 4.Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге, кәбестә, алма. | Һәрберсе 15 данә |
| 5. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар. | 1.Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): «Өч аю»: әти аю, әни аю, бала аю.<br>2. Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): «Кем нәрсә ярата»: песи, эт, аю, куян, кәҗә, әтәч.<br>өстәл (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>урындык (зур, уртача зурлыкта, кечкенә);<br>карават (зур, уртача зурлыкта, кечкенә). | Һәрберсе 1 данә<br><br>Һәрберсе 1 данә |

## Мәктәпкә әзерлек төркеменең «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар" укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар.

| | | |
|---|---|---|
| 1.А 4 форматында күрсәтмә рәсемнәр. | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 1 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 1 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабй йоклый. | Һәрберсе 1 данә |
| 2. А 5 форматында таратма рәсемнәр. | Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак. | Һәрберсе 15 данә |
| | Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). | Һәрберсе 15 данә |
| | Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабай йоклый. | Һәрберсе 15 данә |
| 8x10 форматындагы пиктограммалар | Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай. | Һәрберсе 15 данә |
